# «Бөтенсоюз пионер лагере “А р т е к”та ял иттем мин ...»

Әнә шулай горурланып сөйлиләр Урманасты Шынталы мәктәбе укучылары Ишниязова Сирень һәм Әхмәдиева Гүзәл.

## «Артек» истәлекәре

Ишниязова Сирень Фәрдус кызының шәхси архивыннан алынды.

**“А р т е к” – дөньядагы барлык балаларның ДУСЛЫК һәм ТУГАНЛЫК, БӘХЕТ һәм ТЫНЫЧЛЫК символы ул!**



Ишниязова Сирень 1967 елның 16 сентябрендә Татарстанның Алексеевск районы Урманасты Шынтала авылында туа. Туган авылындагы мәктәпкә укырга бара. Бала чактан ук яшьтәшләре арасында яхшы укуы, бераз олыларчарак холкы-фигыле белән аерылып тора. Чын татарча өлгер һәм зирәк кызны сыйныфташлары да, укытучылар да үз итә. Хикмәт шунда, ундүрт яшьлек Сирень бик яшьли авыл “тарихына эләгә - атаклы “Артек” пионерлагеренда ял итеп кайта.

«1981 ел. Мәктәпнең VI1сыйныфын тәмамладым. Алексеевск районына бүлеп бирелгән юлламаның миңа эләгүе бик зур шатлык булды. Әтием мине Казанга кадәр озатып куйды. Шунысы хәтердә калган: әнием юлга 1 литрлы банкага май белән бал болгатып җибәргән иде. Поездда барганда шул ризык 5 вожатыйга һәм 40 балага ипигә ягып ашарга җитте.Поезд белән Мәскәүгә бардык. Анда экскурсия булды. Аннан 1980 нче елгы Олимпия аюын сатып алдым. Аннан тагын поезд белән киттек. Шулай итеп, мин илебезнең иң абруйлы пионер лагерена - Артекка барып эләктем. “Кипарисная”да ял иттем. Вожатыебыз Аниса Гаффановна иде.Отрядта мин звеньевая идем.Чаллы кызы Ольга Князева, Казаннан Айрат Бариев белән дуслашып киттек. Шактый еллар хатлар языштык. Төрле чараларда актив катнаштым. Фототүгәрәккә йөрдем. Тагын шунысы истә

калган: төрле республикалардан килгән балалар үз республикаларын яклап чыгыш ясарга тиеш иде. Мин татар халык биюен биедем.

Бераз тарихка күз салыйк: 1925 нче елның 16 июнендә АЮ-Даг итәгендәге палаткалар шәһәрчегендә Кызыл байрак күтәрелә. Бу – Бөтенсоюз пионер лагере “Артек”ның ачылуы хөрмәтенә иде.

“А р т е к” – дөньядагы барлык балаларның ДУСЛЫК һәм ТУГАНЛЫК, БӘХЕТ һәм ТЫНЫЧЛЫК символы ул!

“Артек” хәтта сугыш вакытында да ябылмаган. Бөек Ватан сугышы елларында ул Мәскәү аша Сталинградка, соңрак 1944 елга кадәр Алтайга күчерелә. Балаларның бер өлеше вакытлыча Казанда һәм Уфада да яшәп ала. 1944 елның апрелендә “Артек” территориясе дошманнардан чистартылгач, лагерь тиз арада торгызылып, августта балаларны кабул итә башлый. Күрәсез, ни авыр сугыш елларында да ул балаларны үзенә туплый алган, шул чакларда да илебез балаларны ял иттерү мөмкинлеген тапкан.

1969 елда инде “Артек”ның 150 бинасы, 3 медицина үзәге, мәктәбе, “Артекфильм” студиясе, 3 бассейны, 7000 урынлы стадионы һәм мәйданчыклары була.

Совет елларында безнең илебездә генә түгел, чит илләрдә дә “Артек”ның дәрәҗәсе искиткеч зур иде. “Артек”ның иң популяр чакларында биредә елына 27 000 бала ял иткән. Леонид Брежнев, Юрий Гагарин, Индира Ганди, Никита Хрущев, Джавахарлал Неру,Отто Шмидт, Пальмиро Тольятти, Хо Ши Мин, Бенджамин Спок, Михаил Таль, Валентина Терешкова “Артек”ның почетлы кунаклары була.

Иң мөһиме — “Артек”чы булу өчен әти-әниеңнең калын кесәсе дә, зур урында эшләве дә әһәмиятле түгел иде.»

(Ишниязова Сирень сөйләгәннәрдән)



Икенче рәттә уңнан беренче – Ишниязова Сирень.

***Я знаю - друзья у меня есть повсюду,***
***Под небом огромным в любых уголках...***

***Артек- это радость,***
***Артек- это чудо,***
***Артек – это дружба***
***На всех языках***



Икенче рәттә уңнан беренче Ишниязова Сирень.